КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2 г. Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@tatar.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«29» 03 2023 г. № 58-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә һәм «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы басылып чыгуга бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 3 декабрендәге 36-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2019 елның 26 августындагы 55-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

19 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 1 июлендәге 21-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2018 елның 5 апрелендәге 8-п

номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында биләү коррупциячел хәтәрләргә бәйле булган, биләгән вакытта дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 16 декабрендәге 45-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы,
урынбасар И.Ф. Миргалимов